Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Иске Алпар авыл җирлегенең Иске Алпар авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2019 елның 24 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 19 номерлы Әлки муниципаль районының «Иске Алпар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 17 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе»карары, 2019 елның 24 ноябрендәге 3 номерлы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлегенең Иске Алпар авылында гражданнар җыены йомгаклау беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлеге составына керүче Иске Алпар торак пунктында гражданнар җыенын үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 90 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
алардан:

- урам утларын урнаштыруга кирәкле материал сатып алуга, электромонтаж эшләренә һәм урам утларын кулланган энергиягә чыгымнарны түләүгә-85 сум;

- урамдагы су белән тәэмин итү системасын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау, проект-смета эшләрен башкару, су башнясы коймаларын буяу, ярымсыргычлар сатып алу, гидрантлар урнаштыру, су башнясы тоту, су анализы өчен түләү, су башнясын кулланган электр энергиясе өчен түләү – 135 сум;

- җирлек эчендәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга һәм ремонтлауга, юлларны ремонтлау өчен кирәкле материаллар сатып алуга һәм кышын урамнарны кардан чистартуга, МТЗ-82 тракторын тотуга һәм ягулык - майлау материаллары сатып алуга-290 сум;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү, контейнерлар сатып алу , ККК булган рөхсәтсез чүплекләрне өемләү һәм бетерү-90 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

**3.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган,1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 90 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
алардан:

- урам утларын урнаштыруга кирәкле материал сатып алуга, электромонтаж эшләренә һәм урам утларын кулланган энергиягә чыгымнарны түләүгә-85 сум;

- урамдагы су белән тәэмин итү системасын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау, проект-смета эшләрен башкару, су башнясы коймаларын буяу, ярымсыргычлар сатып алу, гидрантлар урнаштыру, су башнясы тоту, су анализы өчен түләү, су башнясын кулланган электр энергиясе өчен түләү – 135 сум;

- җирлек эчендәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга һәм ремонтлауга, юлларны ремонтлау өчен кирәкле материаллар сатып алуга һәм кышын урамнарны кардан чистартуга, МТЗ-82 тракторын тотуга һәм ягулык - майлау материаллары сатып алуга-290 сум;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү , контейнерлар сатып алу, ККК булган рөхсәтсез чүплекләрне өемләү һәм бетерү - 90 сум.

4.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Алпар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Иске Алпар авыл җирлеге башлыгы: Р. Р. Сәлахов